# Тарихи экскурс

18нче май – Халыкара музейлар көне. Музейлар көнендә музейга бармый калып буламыни инде? 8нче балалар китапханәсе хезмәткәрләре 21нче мәктәп укучылары өчен «Автомобиль гаскәрләренең сугышчан дан тарихы музее»нда туган якны өйрәнүче язучы Мансур Сафин белән тарихи экскурс оештырды.

Мансур Сафин балаларга хәрби автомобильләр барлыкка килү тарихы, аларның камилләшүе турында сөйләде, шулай ук сугыш чорында автотранспортның зур роль уйнавын билгеләп үтте. Бөек Ватан сугышы, фронтта һәм дошман тылында якташларыбызның батырлыгы, хәрби дәрәҗәләр турында да.

Каска, граната, флягалар, төрле тарихи чор кораллары һәм сугышчыларның шәхси әйберләре...барысы да кызыксыну уятты.

**Лайсән ХӘЕРТДИНОВА,**
*Чаллы шәһәре. Автор фотосы.*

